РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«8» июня 2024ел

№ 82

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 июнендәге 367 номепрлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карары белән расланган Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә расларга:

«3. Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 31700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 29500 |
| Бүлек башлыгы | 25700 |

| | |
|---|---|
| Әйдәп баручы бухгалтер | 23300 |
| Бухгалтер | 22000 |

Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә кертү шарты булып, структурада һәрберсендә кимендә 5 берәмлек штатлы 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карары белән расланган Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары түбәндәге кеше саны белән | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | - | 25000 сум |
| Бухгалтер | 22500 сум | 22500 сум |

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин